**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 26 декабрендәге 4686 номерлы карары**

# «Дуслык Тәпие» шәһәр проектында катнашучы муниципаль белем бирү учреждениеләре арасында конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен гамәлгә кертә торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 30 декабрендәге 3985 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган Казан шәһәре Башкарма комитетының норматив хокукый актларына карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары нигезендә, йортсыз хайваннарга карата гуманлы һәм җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру процессында мәгариф оешмаларының активлыгын арттыру һәм аларның ирекле инициативаларына ярдәм итү максатыннан **карар бирәм**:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә «Дуслык Тәпие» шәһәр проектында катнашучы муниципаль белем бирү учреждениеләре арасында конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.
2. «Дуслык Тәпие» шәһәр проектында катнашучы муниципаль белем бирү учреждениеләре арасында конкурс үткәрү өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә субсидияләр бирү буенча вәкаләтле орган итеп Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсен билгеләргә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов) «Дуслык Тәпие» шәһәр проектында катнашучы муниципаль белем бирү учреждениеләре арасында конкурсны оештыру, үткәрү һәм конкурсның кызыксындыру түләүләренә 2 650 мең сум күләмендәге чыгымнарны «Мәгарифне, гомумшәһәр чараларын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар» 02 602 43600 максатчан статьясы, 0709 бүлеге буенча 2025 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең бюджет язмасы чикләрендә тормышка ашырырга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 22 декабрендәге 4299 номерлы «“Дуслык тәпие” грант бәйгесен үткәрү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 26 декабрендәге
4686 номерлы карары белән
расланды

**«Дуслык Тәпие» шәһәр проектында катнашучы муниципаль белем бирү учреждениеләре арасында конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә белем бирү оешмаларының активлыгын арттыруга һәм йортсыз хайваннарга карата гуманлы һәм җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру процессында аларның ирекле инициативаларына ярдәм итүгә юнәлдерелгән субсидия алуга Казан шәһәренең муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен конкурс (алга таба – Конкурс, учреждение) үткәрүнең максатларын, бурычларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Әлеге нигезләмә өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

- белем бирү учреждениесе – Конкурста катнашучы булып торучы, Казан шәһәре территориясендә урнашкан муниципаль бюджет яки автоном белем бирү учреждениесе;

- субсидия – «Дуслык Тәпие» шәһәр проектында катнашучы белем бирү учреждениеләренә бирелә торган акчалар;

- Конкурста катнашучы – мәктәпкәчә, башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирүнең төп белем бирү программаларын һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын бертигез дәрәҗәдә гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениесе;

- гариза – әлеге Нигезләмәнең 2.5, 2.6, 2.7 пунктлары нигезендә Конкурста катнашу өчен Конкурста катнашучы тарафыннан тапшырыла торган документлар;

- конкурс комиссиясе – конкурста катнашучыларның гаризаларын бәяли һәм конкурста җиңүчеләрне һәм субсидияләр күләмен билгеләү функцияләрен башкара торган коллегиаль орган.

1.3. Конкурсны уздыруның максаты – әлеге субсидия бирелә торган нәтиҗәләргә ирешүнең иң яхшы шартларыннан чыгып, субсидия алучыны билгеләү.

1.4. Конкурсның бурычлары:

- мәгариф учреждениеләрендә балаларга һөнәри юнәлеш бирү эшен оештыру, хайваннар белән бәйле һөнәрләрне популярлаштыру, сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар белән эшләү буенча иң яхшы тәҗрибәләрне һәм инновацион формаларны ачыклау һәм җәелдерү, шулай ук йортсыз хайваннарга һәм приютлардагы хайваннарга ярдәм күрсәтү буенча волонтерлык эшчәнлегенә җәлеп итү;

- мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә, мәктәпләрдә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендә укучы балаларның игътибарын йортсыз хайваннар проблемаларына җәлеп итү;

- социаль видеороликлар аша халыкка аңлату эшләре алып бару һәм фотокүргәзмәләр оештыру.

1.5. Субсидия алучыларга субсидия бирүнең максаты – йортсыз хайваннарга карата гуманлы һәм җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру процессында белем бирү оешмаларының активлыгын арттыру һәм аларның ирекле инициативаларына ярдәм итү, шулай ук аларның уңай тәҗрибәсен тарату.

1.6. Субсидияне конкурс комиссиясе тарафыннан Конкурста җиңүче дип танылган һәм вәкаләтле орган – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе белән субсидия бирү турында килешү төзегән Конкурста катнашучылар ала.

1.7. Субсидия максатчан билгеләнештә була һәм аны алучы тарафыннан әлеге нигезләмәдә каралмаган максатларга файдаланыла алмый.

1.8. Субсидия 2025 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең бюджет язмасы чикләрендә бирелә.

1.9. Субсидия бирү өчен бүлеп бирелгән бюджет акчаларының баш бүлүчесе булып Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе (алга таба – Вәкаләтле орган) тора.

## II. Конкурсны уздыру тәртибе

2.1. Конкурс биш номинация буенча уздырыла:

- «Кеше эткә дус»;
- «Айболит һәм башкалар»;
- «Инклюзив белем бирүдә зоотерапия»;
- «Зооволонтер»;
- «Дустым, тәпиеңне бир!» (видеороликлар һәм фотолар).

2.2. Конкурста катнашуга дәгъва кылучы учреждение субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айга кадәрге айның 1 нче көненә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- учреждениенең салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча түләнмәгән бурычы юк;

- учреждениенең Казан шәһәре бюджетына субсидияләр, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычы юк, моңа үзгәртеп оештыру яисә ябу буенча чаралар үткәрүгә, авария хәлен (гадәттән тыш хәлне) булдырмауга, авария хәле (гадәттән тыш хәл) килеп чыккан очракта, аның нәтиҗәләрен бетерүгә һәм торгызу эшләрен башкаруга субсидия бирү очраклары керми;

- учреждениенең Казан шәһәре бюджетына законлы рәвештә гамәлгә кергән суд актлары, башкарма документлар, шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы, җирле администрациянең муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән башка очракларда бурычны каплауга бирелә торган субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычы юк.

2.3. Сайлап алу заявканы һәм рәсмиләштерелгән проектларны тапшыру һәм әлеге нигезләмәдә билгеләнгән конкурс материалларын бәяләү рәвешендә үткәрелә.

2.4. Конкурс үткәрү вакыты: 2025 елның 25 декабреннән 28 декабренә кадәр.

2.5. Конкурсның читтән торып катнашу этабында катнашу өчен катнашучылар gdebc-kzn@yandex.ru электрон почта адресына *.zip яки *.rar форматта архивланган бер файл белән «“Дуслык тәпие” конкурсы» тамгасы белән түбәндәге материалларны юллыйлар:

- әлеге нигезләмәнең 1 номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча гариза;

- әлеге нигезләмәнең 2 номерлы кушымтасы нигезендә эшләнгән проект тасвирламасы;

- гариза бирелгән айның беренче көненә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә;

- учреждениенең әлеге нигезләмәнең 2.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документлар;

Конкурста катнашучы конкурс материалларын тапшырганда Конкурста катнашучы турында мәгълүматны, Конкурста катнашучы бирә торган гариза турында, Конкурста катнашучы турында тиешле конкурс белән бәйле башка

мәгълүматны Интернет челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык бирә.

Конкурста катнашучы гаризада бирелгән мәгълүматның дөреслеге өчен җаваплы.

2.6. Конкурста катнашучылар тапшырган документларга түбәндәге таләпләр куела:

- «Кеше этнең дусты» номинациясе – белем бирү программалары / маршрутлары, этләр белән сак һәм куркынычсыз аралашу чаралары, хуҗасыз хайваннар белән бәйле проблемаларга игътибарны җәлеп итү, шәһәрдә хуҗасыз этләр һәм мәчеләр санын киметү өчен шартлар тудыру һ.б.;

- «Айболит һәм башкалар» номинациясе – белем бирү программалары / маршрутлары, балаларга һөнәри юнәлештә белем бирү чаралары, хайваннар белән бәйле һөнәрләр белән танышу, балалар һәм яшүсмерләр арасында шундый һөнәрләрне популярлаштыру өчен әлеге өлкәдәге белгечләрне чакыру һ.б.;

- «Инклюзив белем бирүдә хайваннар ярдәмендә дәвалау» номинациясе – белем бирү программалары/маршрутлары, сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар белән эшләү чаралары;

- «Хайваннарга ярдәм итүче волонтер» номинациясе – белем бирү программалары/маршрутлары, әйләнә-тирә мохиткә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү чаралары, тере объектлар белән эшләү күнекмәләрен булдыру, аларны карау һәм тәрбияләү;

- «Дустым, тәпиеңне бир!» номинациясе:

а) видеороликлар (Конкурс темасы буенча Word текст форматында язылган видеоролик сценарие җибәрелә (New Roman шрифты, үлчәме 14, юллар арсындагы интервал 1, сул яктан, уңнан, өстән, астан чигенүләр –2 см). Җиңүчеләр үз сценарие буенча социаль видеоролик төшерү өчен субсидия алачак;

б) фотографияләр (хуҗасыз хайваннар белән бәйле проблемаларны чагылдыра торган төрле сюжет линияләренә караган 15 электрон фотография җибәрелә, фотографияләрнең форматы: JPG, максималь сыйфаты – 300 пиксель/дюйм. Әлеге номинациядә җиңүчеләр фотокүргәзмәне оештыру өчен үзләренең фотографияләрен матурлап ясау һәм бастырып чыгару өчен субсидия алачаклар).

Конкурс документациясенә кертелә торган документларның электрон күчермәләре (сканерлау юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документлар) мәгълүматны һәркем карый ала торган программа тәэминаты чаралары белән бөтен документны карау мөмкинлеген тәэмин итә

торган киң таралган ачык форматларда, аларның эчтәлеге белән махсус программа яисә технологик чаралардан башка танышырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланмаган яисә якланмаган булырга тиеш.

2.7. Гариза һәм аның белән бергә тапшырыла торган документлар фактта алынган көнне теркәлә. Гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң Вәкаләтле органга кергән гариза теркәлми һәм Конкурста катнашырга рөхсәт ителми.

Гаризалары Вәкаләтле органга гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң кергән Конкурста катнашучыларга Конкурста катнашуга кертелмәү турында Вәкаләтле орган тарафыннан электрон почта адресына хәбәр ителә.

2.8. Вәкаләтле орган түбәндәге очракларда гаризаны кире кагу турында карар кабул итә:

- Конкурста катнашучының әлеге тәртипнең 1.2, 2.2 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

- Конкурста катнашучы тарафыннан тапшырылган документларның документларга карата әлеге нигезләмәнең 2.5, 2.6 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- Конкурста катнашучы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

2.9. Гаризада хәреф хатасы, басма хаталар, орфографик һәм арифметик хаталар булу Конкурста катнашуга рөхсәт итмәү өчен нигез була алмый.

2.10. Гаризаларны тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килми дип танылган Конкурста катнашучыларга бу хакта тикшерү тәмамланган көннән алып биш эш көне эчендә Вәкаләтле орган тарафыннан электрон почта адресына хәбәр ителә.

Кирәкле барлык документлар тапшырылмаган яки алар тиешенчә тутырылмаган очракта, Вәкаләтле орган, гаризаларны бәяләү вакыты тәмамланырга кимендә бер эш көне кала, күрсәтелгән документларны ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү өчен кире кайтара.

Хәбәрнамә Конкурста катнашучыга Вәкаләтле органга электрон документ рәвешендә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яисә Вәкаләтле органга язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Конкурста катнашучының җитешсезлекләрне бетерү вакыты әлеге хәбәрнамә мәгариф учреждениесендә теркәлгән көннән алып бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

2.11. Тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килә дип танылган гаризалар тикшерү тәмамланган көннән алып бер эш көне эчендә Вәкаләтле орган тарафыннан конкурс комиссиясенә тапшырыла.

## III. Конкурс комиссиясе

3.1. Конкурс комиссиясе Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе әмере белән төзелә һәм комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, секретареннән, әгъзаларыннан тора. Конкурс комиссиясе составына комиссиянең кимендә өч әгъзасы керә.

Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, аның карарын раслый. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның функцияләрен конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе рәисе йөкләмәсе буенча конкурс комиссиясе утырышын әзерләүне оештыру функцияләрен башкара.

3.2. Конкурс комиссиясе әгъзасының җиңүчене билгеләгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган шәхси кызыксынуы барлыкка килгән очракта, ул, конкурс гаризалары карап тикшерелә башланганчы, бу хакта конкурс комиссиясе рәисенә хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы конкурс комиссиясе эшендә катнашмый.

3.3. Конкурс комиссиясе:

- Конкурста катнашуга рөхсәт ителгән гаризаларны карап тикшерә;
- гаризаларны әлеге нигезләмәнең 3 номерлы кушымтасындагы бәяләү битләрендә билгеләнгән критерийлар нигезендә бәяли;
- Конкурста җиңүчеләрне билгели.

3.4. Конкурс номинацияләрендә җиңүчеләр ачыкланганда баллар саны тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисе куйган бәяләр хәлиткеч дип санала.

3.5. Конкурс комиссиясе карары катгый һәм үзгәртелми.

## IV. Гаризаларны бәяләү һәм Конкурста җиңүчеләрне билгеләү тәртибе

4.1. Гаризаларны карап тикшерү конкурс комиссиясе утырышында конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе утырышы әлеге нигезләмәнең 2.4 пунктында билгеләнгән срокларда урында яки читтән торып уздырыла. Конкурс комиссиясе утырышы комиссия әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашкан очракта хокуклы булып санала.

4.2. Гаризаларны бәяләү конкурс комиссиясе утырышында конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан әлеге нигезләмәнең 3 номерлы кушымтасындагы гаризаларны бәяләү критерийлары нигезендә баллар куйю юлы белән башкарыла.

4.3. Әлеге нигезләмә һәм критерийлар нигезендә Конкурста сайлап алуны уңышлы узган Конкурста катнашучыларга номинацияләр буенча субсидия бирелә.

4.3.1. Дүрт номинациядә җиңүчеләргә: «Кеше эткә дус», «Айболит һәм башкалар», «Инклюзив белем бирүдә зоотерапия», «Зооволонтер»:

- 1 нче урын – 200 000 (ике йөз мең) сум;
- 2 нче урын – 100 000 (йөз мең) сум;
- 2 нче урын – 100 000 (йөз мең) сум;
- 3 нче урын – 50 000 (илле мең) сум;
- 3 нче урын – 50 000 (илле мең) сум.

4.3.2. «Дустым, тәпиеңне бир!» номинациясендә:

- «Видеоролик» номинациясендә җиңүче – 100 000 (йөз мең) сум;
- «Видеоролик» номинациясендә җиңүче – 100 000 (йөз мең) сум;
- «Фотоэшләр» номинациясендә җиңүче – 50 000 (илле мең) сум;
- «Фотоэшләр» номинациясендә җиңүче – 50 000 (илле мең) сум.

4.4. Конкурс йомгаклары буенча бер эш көне эчендә беркетмә төзелә, аны конкурс комиссиясе имзалый. Беркетмәдә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

- Конкурста катнашучыларны бәяләү көне, вакыты;
- Конкурста катнашучылар турында мәгълүмат;
- килешүләр төзелә торган субсидия алучыларның атамасы һәм аларга бирелә торган субсидияләрнең күләмнәре.

Конкурс йомгаклары буенча һәм йомгаклау беркетмәсе нигезендә бер эш көне эчендә Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе әмере чыгарыла, ул электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә Казан шәһәренең барлык белем бирү оешмаларына җиткерелә.

## V. Субсидияне бирү, аннан файдалануны контрольдә тоту, хисаплар бирү, субсидияне алучылар тарафыннан кире кайтару тәртибе һәм хисапка карата таләпләр

5.1. Конкурста җиңүчеләр исемлеген раслый торган Конкурс комиссиясе беркетмәсе Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе белән субсидия алучы арасында Казан шәһәре Башкарма комитеты Финанс идарәсенең 2023 елның 12 гыйнварындагы 9 номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Казан шәһәренең муниципаль бюджет яисә автоном учреждениесенә Казан шәһәре бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы килешүнең типлаштырылган формаларын раслау хакында»гы боерыгы белән расланган форма буенча субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү өчен нигез булып тора.

5.2. Килешү төзү өчен конкурста җиңүче дип танылган учреждение конкурс йомгаклары турында мәгълүмат игълан ителгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә, максатчан субсидия алу өчен тапшырыла торган документлар исемлеге нигезендә тапшырылган документларның исемлеген кушымта итеп биреп, әлеге Нигезләмәнең 4 номерлы кушымтасында билгеләнгән форма буенча гариза тапшыра. Документлар исемлегенә түбәндәгеләр керә:

- субсидия суммасын исәпләү-нигезләүне, шул исәптән тиешле эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә), чаралар үткәрүгә, милек (күчемсез милектән кала) сатып алуга башлангыч сметаны кертеп, бюджет акчаларын әлеге нигезләмәнең 1.3, 1.5 пунктларында билгеләнгән максатларга бирү кирәклеген нигезләүне, шулай ук тәэминатчыларның (подрядчыларның, башкаручыларның) тәкъдимнәрен, статистик мәгълүматларны һәм (яки) башка мәгълүматны үз эченә алган аңлатма язуы;

- субсидия бирү максаты булып чаралар, шул исәптән конференцияләр, симпозиумнар, күргәзмәләр үткәрү торган очракта, чаралар программасы;

- субсидия бирү максаты милек сатып алу булган очракта, сатып алырга планлаштырылган милек турында мәгълүмат.

5.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе:

а) гаризаны килеп ирешкән көнне терки;

б) әлеге нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән документларның тулылыгын, алардагы мәгълүматның җитәрлек булуын һәм дөреслеген карап тикшерә;

в) гаризаны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә субсидия бирү яки бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Кирәкле барлык документларны тапшырмаган яисә аларны тиешенчә тутырмаган очракта, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, карап тикшерү вакыты тәмамланырга кимендә ике эш көне кала, ачыкланган җитешсезлекләрне төзәтү өчен әлеге документларны кире кайтара.

Хәбәрнамә учреждениегә Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә электрон документ рәвешендә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яки Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Учреждение тарафыннан җитешсезлекләрне төзәтү вакыты – әлеге хәбәрнамә мәгариф учреждениесендә теркәлгәннән соң биш эш көненнән артык түгел.

5.4. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

- учреждениенең тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләве;

- агымдагы финанс елында структур бүлекчәнең бюджет язмасында каралган бюджет йөкләмәләре лимитларының максатчан субсидияләр бирүгә тулысынча бүленүе.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, учреждениегә мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә, субсидия бирүдән баш тарту сәбәбен күрсәтеп, баш тарту турында хәбәрнамә җибәрелә.

Баш тарту турында хәбәрнамә учреждениегә электрон документ рәвешендә структур бүлекчәгә килгән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ формасында яки структур бүлекчәгә язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресына язма рәвештә җибәрелә.

Баш тарту өчен нигез булып торган җитешсезлекләр төзәтелгән очракта, учреждение документларны кабат җибәрергә хокуклы.

5.5. Килешүдә субсидия бирүнең максатлары, субсидия бирүнең конкрет, үлчәнерлек булырга тиешле нәтиҗәләренең һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрнең кыйммәтләре, тиешле программалар, проектлар нәтиҗәләренә ирешкәндә (мондый детальләштерү мөмкинлеге

булганда) алу планлаштырыла торган матди һәм матди булмаган объектлар һәм (яисә) хезмәтләр өлешендәге күрсәткечләрнең кыйммәтләрен дә кертеп, субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы, субсидия күләме, субсидия күчерү сроклары (графигы), хисап бирү сроклары, учреждение тарафыннан максатларны үтәмәгән очракта субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм сроклары, килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе, килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән гамәлгә куючы органга бюджет акчаларын алучы буларак субсидия бирүгә элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары киметелгән очракта, гамәлгә куючы орган карары буенча килешүне берьяклы тәртиптә вакытыннан алда туктату өчен нигезләр, шул исәптән: учреждениене үзгәртеп оештыру (кушылу рәвешендәге үзгәртеп оештырудан тыш) яисә учреждениене бетерү, учреждение тарафыннан хокукый актта һәм (яисә) килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозу, учреждениенең килешүне берьяклы тәртиптә өзүен тыю.

Килешү проектын төзү субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары булганда Вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла. Килешү финанс органы тарафыннан расланган типлаштырылган форма буенча төзелә.

5.6. Конкурста җиңүче Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф Идарәсе тарафыннан имзаланган килешүнең ике нөсхәсен алган көннән соң өч эш көне эчендә аларны имзалый һәм килешүгә кул кую турында Вәкаләтле органга электрон почта адресы буенча хәбәр итә.

Конкурста җиңүче килешүгә кул кую турында хәбәрнамә җибәрелгән көннән алып өч эш көне эчендә килешүнең имзаланган нөсхәсен вәкаләтле органга шәхсән үзе тапшыра.

5.7. Килешү ике як тарафыннан да имзаланганнан соң төзелгән дип санала.

5.8. Субсидия алучы имзалаган килешү әлеге нигезләмәнең 5.6 пунктында билгеләнгән вакыт эчендә тапшырылмаган очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип санала һәм субсидия алу хокукыннан мәхрүм ителә.

5.9. Субсидия түбәндәге чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен бер мәртәбә бирелә:

а) мастер-класслар, мәгърифәтчелек чаралары, акцияләр, укучылар, укытучылар, ата-аналар өчен белем бирү лекцияләре, курслар үткәрү;

б) ташланган хайваннар проблемасын популярлаштыру максатыннан күрсәтмә-агитация материалы ясау;

в) проектны гамәлгә ашыру өчен белем бирү оешмасын материаль-техник җиһазлау;

г) хайваннар дөньясын яклау өлкәсендә чакырылган спикерлар, белгечләр, профессиональ фотографлар, видеографлар хезмәтенә түләү;

д) типография, канцелярия хезмәтләре.

5.10. Белем бирү учреждениеләре өчен төрле чаралар үткәрү һәм (яки) товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу субсидия бирүнең нәтиҗәләре булып тора.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр түбәндәгеләр:

а) ташланган хайваннар проблемасын популярлаштыру өчен кимендә бер сатып алынган товар, эш, хезмәт;

б) шул темага караган теге яки бу чарада катнашкан кимендә бер укучы, укытучы яки ата-ана.

5.11. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе килешү төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының территориаль бүлегендә ачылган субсидияне алучының исәп-хисап счетына субсидияне күчерә.

5.12. Субсидия алучы Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында, хисаптан соң килә торган елның 10 гыйнварыннан да соңга калмыйча килешүдә каралган форма буенча һәм срокларда хисап тапшыра.

5.13. Хисап бирелә торган финанс елында файдаланылмаган максатчан субсидияләрнең калган өлешләре Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелергә тиеш.

5.14. Хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе Казан шәһәре Башкарма комитетынең Финанс идарәсенә, килешүдә билгеләнгән вакытларда кабул ителгән чыгым йөкләмәләре булмау сәбәпле, максатчан субсидия акчаларының хисап елы булган финанс елында файдаланылмаган һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кайтарылырга тиешле калган өлеше турында мәгълүмат җибәрә.

5.15. Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан субсидияләр булган учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән керемнәрне максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларга ирешү өчен агымдагы финанс елында файдалану турындагы карар, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе белән килештереп, учреждение тарафыннан кабул ителә.

Максатчан субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган,

учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән акчалардан агымдагы финанс елында файдалану турында карар кабул итү өчен учреждениеләр Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә учреждениенең учреждениеләр тарафыннан агымдагы финанс елының 1 гыйнварына элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан алынган акча финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган үтәлмәгән йөкләмәләре булуы турында мәгълүматны, шулай ук учреждениенең әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуын һәм күләмен раслый торган документларны (документларның күчермәләрен) акча килеп ирешкәннән соң өч эш көне эчендә тапшыра.

Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат килеп ирешкән көннән соң 10 эш көне эчендә килештерү/килештермәү турында карар кабул итә.

5.16. Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле орган субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, үтәлешен тикшерә.

Муниципаль финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрәләр.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен бәяләү мөмкин булмаса, урынга чыгып тикшерү үткәрелә. Субсидия алучы контроль өчен керү мөмкинлеген тәэмин итәргә, шулай ук күчмә тикшерү барышында субсидия бирү белән бәйле соралган документларны тапшырырга тиеш.

5.17. Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча учреждениенең максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәве ачыкланган очракта, учреждение максатчан субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта, шулай ук учреждение әлеге нигезләмәнең II бүлегендә билгеләнгән тәртиптә максатчан субсидиядән файдалану турында хисаплар тапшырмаган очракта, максатчан субсидия Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

5.18. Максатчан субсидияне яки аның бер өлешен кире кайтару таләбе аны алган көннән башлап 30 календарь көн эчендә учреждение тарафыннан үтәлергә тиеш.

Субсидияне кире кайтару турындагы таләп билгеләнгән вакыт эчендә үтәлмәгән очракта, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе аны Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтүне тәэмин итә.

5.19. Учреждение җитәкчесе максатчан субсидияләрдән килешүдә

каралган шартларда һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә файдаланган өчен җавап тота.

## VI. Элемтәләр

«Шәһәр балалар экология-биология үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең адресы: 420061, Казан шәһәре, Космонавтлар урамы, 57 йорт. Элемтә өчен телефоннар: +7 (843) 273-48-55, +7 (843) 223-23-80 (өст.211).

«Дуслык Тәпие» шәһәр проектында катнашучы муниципаль белем бирү учреждениеләре арасында конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә 1 номерлы кушымта
(Форма)

**Муниципаль автоном һәм бюджет белем бирү учреждениеләре өчен «Дуслык Тәпие» конкурсында катнашуга гариза**

1. Конкурс номинациясенең исеме ____________________________________________
_____________________________________________

2. Проектның исеме _____________________________________

3. Проект җитәкчесе турында мәгълүмат:

Фамилиясе, исеме, атасының исеме _____________________________________

Вазифасы _____________________________________

Элемтә өчен телефон номеры _____________________________________

Электрон почтасы _____________________________________

4. Гариза бирүче оешманың исеме _____________________________________
_____________________________________

5. Гариза бирүче оешма житәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазифасы ______________________________________________

6. Партнерлар ______________________________________________

7. Проектның дәвамлылыгы (айларда) ______________________________________________

8. Проектның гомуми бюджеты (сумнарда) ______________________________________________

9. Сорала торган сумма (сумнарда) ______________________________________________

10. Проектның кыскача тасвирламасы (0,25 биттән артмаска тиеш)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

_________________________

Әлеге гариза белән минем тарафтан бирелә торган мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Проект житәкчесенең имзасы:

_____________________________

Дата: ______________________ Мөһер урыны (оешмалар өчен)

«Дуслык Тәпие» шәһәр проектында
катнашучы муниципаль белем бирү
учреждениеләре арасында конкурс
үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә
2 номерлы кушымта

**Проектның тасвирламасы**

Титул бите.

Оешманың тасвирламасы (бер биттән артмаска тиеш): гариза бирә торган оешманың тарихы, максатлары, бурычлары һәм төп эшчәнлегенең кыскача тасвирламасы, аның алдагы ике елга перспективалары.

Проектның актуальлеге (1,5 биттән артмаска тиеш): оешманың сайланган темага мөрәҗәгать итү сәбәпләрен, әлеге проектның ни өчен кирәк булуын, аның проблеманы ничек хәл итәчәген тасвирлау.

Проектның максаты һәм бурычлары (0,5 биттән артмаска тиеш): тасвирлама куелган проблеманы хәл итү өчен оешма үз алдына куйган максатларны, әлеге максатларга ирешү өчен хәл итү зарур булган бурычларны эзлекле рәвештә санап чыгуны үз эченә ала.

Проектны гамәлгә ашыру вакыты.

Проектны гамәлгә ашыру этаплары (әзерлек, төп, йомгаклау).

Проектны гамәлгә ашыруның эш планы. Бүлек, түбәндәгеләрне күрсәтеп, чаралар план-графигын тәкъдим итә:

- проектны гамәлгә ашыру өчен планлаштырылган чаралар исемлеге;
- күрсәтелгән чараларны уздыру вакыты;
- чараларны башкаручыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме;
- чараларны финанслау чыганаклары (бюджет статьялары, комментарийлар).

Проект сметасы.

Конкрет көтелә торган нәтиҗәләр (бер биттән дә артмаска тиеш): проектны гамәлгә ашыру барышында ирешү планлаштырыла торган сан һәм сыйфат күрсәткечләрен тасвирлау.

«Дуслык Тәпие» шәһәр проектында
катнашучы муниципаль белем бирү
учреждениеләре арасында конкурс
үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә
3 номерлы кушымта

**Конкурсның бәяләү критерийлары**

1) Проект тасвирламасының сыйфаты һәм тулылыгы: актуаль булуы, үзенчәлеге, күрсәтелгән максатларның һәм бурычларның төгәл булуы, проектны гамәлгә ашыруның нәтиҗәле технологиясе (10 балл);

2) проектның логик яктан бәйләнеше һәм гамәлгә ашырылу дәрәҗәсе, проект чараларының максатларга, бурычларга һәм көтелгән нәтиҗәләргә туры килүе (10 балл):

- проектның максаты ачыкланган проблеманы хәл итүгә юнәлтелгән;

- бурычларны үтәү проект максатына ирешүгә китерә;

- календарь планның барлык чараларын гамәлгә ашыру проектның күрсәтелгән көтелгән нәтиҗәләренә ирешергә мөмкинлек бирә;

3) проектны гамәлгә ашыру өчен планлаштырыла торган чыгымнарның һәм аның көтелгән нәтиҗәләренең нисбәте, мондый нәтиҗәләрнең дөреслеккә туры килүе, ирешерлек булуы һәм аларны билгеле бер күрсәткечләр нигезендә бәяләү мөмкинлеге (5 балл);

4) оешманың проектны гамәлгә ашыруга керткән өлеше һәм җәлеп ителә торган өстәмә ресурслар, проектның алга таба үсеш перспективалары, грант акчалары белән ярдәм күрсәтелмәгәндә аның яңа шартларда тотрыклы эшләүгә сәләте (10 балл):

- оешманың үзе керткән өлеше дәрәҗәсе һәм аның чынлыктагы мөмкинлекләре;

- проектның партнерлар тарафыннан финанслану күләме;

- грант акчаларын файдаланганнан соң, оешма проект юнәлешендәге эшчәнлек үсешен һәм аның нәтиҗәләре белән эшләүне ни дәрәҗәдә төгәл итеп күзаллый;

5) проект командасының планлаштырыла торган эшчәнлек буенча тәҗрибәсе һәм компетенциясе туры килү (5 балл):

- проектка җәлеп ителгән кешеләр саны нигезләнгәнме;

- аларның барысының да күрсәтелгән вакыт аралыгында һәм бюджетта каралган шартларда проект чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле тәҗрибәсе һәм компетенциясе бармы;

6) конкурста катнашучыларның Интернет челтәрендә мәгълүмат ягыннан ачык булуы һәм активлыгы (edu.tatar.ru сайтында, «ВКонтакте» социаль челтәре аккаунтларында, учреждениеләр сайтларында) (10 балл);

7) сюжет линиясе булу (видеороликлар һәм фотографияләр өчен), конкурс тематикасына һәм нигезләмә таләпләренә туры килү.

«Дуслык Тәпие» шәһәр проектында
катнашучы муниципаль белем бирү
учреждениеләре арасында конкурс
үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә
4 номерлы кушымта
(Форма)

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан
субсидия алу өчен гариза**

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүче | |
| 2 | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры | |
| 3 | Төп дәүләт теркәү номеры | |
| 4 | Юридик адресы | |
| 5 | Телефон номеры | |
| 6 | Электрон почта адресы | |
| 7 | Җитәкче | |
| 8 | Субсидия күләме, сумнарда | |
| 9 | Субсидия күчерү өчен реквизитлар | |
| 10 | Әлеге гариза белән, субсидия алу мөмкинлеген бирә торган дөрес булмаган мәгълүматлар тапшырган өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык барлыгы турында хәбәр ителде.<br>_________________<br>(имза) | |
| 11 | Учреждениенең нигезләмәнең 2.2 пунктында каралган таләпләргә туры килүен раслыйм | |
| 12 | Субсидия бирү шартлары белән таныштым һәм нигезләмә нигезендә документлар исемлеге буенча кирәкле документларны тапшырам | |

Директор
___________________________________________________________________________
(имзасы, вазифасы, фамилиясе һәм инициаллары)

Гариза бирү вакыты: «____» ____________ 20___ ел.